Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең
Сөләй авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

29 ноябрь 2025 ел № 7

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә», 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 28 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2025 елның 29 ноябрендә сәгать 00 минутта булган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлеге Сөләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны (вак таш түшәүне)?»

Соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 427 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 215 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 215 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлеге Сөләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны (вак таш түшәүне)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Сөләй авылы, Совет урамы, 53А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сөләй авыл җирлеге башлыгы А.З. Бикбаев